# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «БОЛГАР ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 7-2 «19» апрель 2021 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 27 октябрендәге 2-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Җир салымы турында» 2020 елның 27 октябрендәге 2-4 номерлы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 2.4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«-коммерциячел булмаган, социаль юнәлешле, иҗтимагый-дәүләт оешмалары тарафыннан бирелә торган җир кишәрлекләренә карата төп максатлары илнең оборона куәтен ныгытуга, милли иминлекне ныгытуга, социаль проблемаларны хәл итүгә, гражданнарны хәрби-патриотик тәрбияләүне оештыруга ярдәм итү булган җир кишәрлекләренә карата».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Яна Тормыш» («Новая жизнь») район газетасында, шулай ук ТР Спас муниципаль районының Интернет челтәрендә рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүмат рәсми сайтында https://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районының
«Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.В. Мөхәммәтов